| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** 12.02.2025 | Казан ш. | **БОЕРЫК** 138-п |

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Яңасала, Чынлы, Бескачанка, Биклән елгаларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Су кодексы, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су саклау зоналары чикләрен һәм су объектларының яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә һәм «Татарстан Республикасының Чүпрәле, Тукай, Спас муниципаль районнары территориясендә урнашкан Яңасала, Чынлы, Бескачанка, Биклән елгаларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү» 2024 елның 9 сентябрендәге № 2024.0311500002124000015 контракт кысаларында башкарылган эшләр нәтиҗәләре буенча боерык бирәм:

1. Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә, әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык сызыклары киңлеген билгеләргә:

1.1. Яңасала елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 40 м.

1.2. Чынлы елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 40 м.

1.3. Бескачанка елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.4. Биклән елгасы:

су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А.Долгов):

2.1. Яңасала, Чынлы, Бескачанка, Биклән елгаларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында белешмәләрне дәүләт су реестрына кертү өчен Федераль су ресурслары агентлыгына җибәрергә;

2.2. территориясендә су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары чикләре билгеләнә торган муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына белешмәләр җибәрергә;

2.3. Яңасала, Чынлы, Бескачанка, Биклән елгаларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында мәгълүматны Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларга үзгәрешләр кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органына) җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В.Веселова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (Р.А.Заһидуллин) әлеге боерыкны, теркәтү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В.Манидичевага йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков